РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«5» август 2020ел. г. Альметьевск № 88

Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының
«Әлмәт шәһәре» муниципаль
берәмлеге карамагындагы муниципаль
торак фондының торак урынына
гомуми өлешле милек хокукында
өлеш сату тәртибе турында»
2020 елның 17 гыйнварындагы
03 номерлы карарына үзгәреш
кертү турында

Муниципаль норматив актларны гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге карамагындагы муниципаль торак фондының торак урынына гомуми өлешле милек хокукында өлеш сату тәртибе турында» 2020 елның 17 гыйнварындагы 03 номерлы карарына карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Карарга 1 нче кушымтаның 2.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Сату-алу шартнамәсен рәсмиләштерү һәм теркәү гамәлдәге законнар таләпләре нигезендә, шул исәптән Россия Федерациясе Граждан кодексында, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Шәһәр
Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Ф. Вәлиев

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Зак. № 301